Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының
бишенче чакырылышының икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

16 октябрь, 2025 ел № 9

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2014 елның 29 декабрендәге 220 номерлы карары белән расланган (2023 елның 12 апрелендәге 223 номерлы, 2023 елның 10 августындагы 252 номерлы, 22 майдагы 404 номерлы үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Юридик ярдәм алуга хокукы булган затлар» II бүлекнең 3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затлар (төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары, төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча белем бирү чорында ике ата-анасын югалткан затлар), шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм, әгәр алар күрсәтелгән затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов